**Сыйныф**: 1-В
**Уку планы буенча татар теленнән:** *66 сәг*
**Атнага:***2 сәг.*

**Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:**

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2018-2019 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2018 ел).

**Дәреслек**. Күңелле татар теле. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмаларының 41нче сыйныфы өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен)
Төзүчеләре:Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина Татар теле китабы. Ике кисәктән тора. Казан. «Татармультфильм» нәшрияты, 2014 ел

“Татар теле һәм әдәби уку” предметы буенча 1 нче сыйныф программасын үзләштерүнең **шәхси нәтиҗәләре**:

– татар теленең дәүләт теле буларак ролен аңлау;

– шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру;

– татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге формалаштыру.

--Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау.

Татар теленә өйрәтүнең **метапредмет (***регулятив, коммуникатив, танып-белү)* **нәтиҗәләре**:

– укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;
– әңгәмәдәшең белән аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру;
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү;
– үрнәк буенча эшли белү;
– аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;
– рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;
– аңлап укый белү;
– укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирү - чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру

Татар теленә өйрәтүнең **предмет нәтиҗәләре**.

**Сөйләшү**

**Диалогик сөйләм.** 1 нче сыйныфта дәрес вакытының 60-70%ын сөйләшүгә өйрәнү ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш

диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм.** Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеклеген сүрәтләп сөйли белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

**Ишетеп аңлау (аудирование)**

Аралашу өчен төп шартларның берсе – әңгәмәдәләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 2 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:

- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда кулана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

**Уку**

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганда сүзлекләр куллана белү.

Дәреслектә уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган экиятләр бирелде. Үзләштерү дәрәҗәсенә карап, укытучы аларны арттыра яки киметә ала.

**Язу**

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбендәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
- бәйрәмнәр белән котлау язу.

**<u>Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр</u>**

**Тыңлап аңлау**

-Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;

-тыңлаганда җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;

-сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү.

-сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү;

-ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

**Диалогик сөйләм:**

-Өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;

-программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына жавап бирү һәм сораулар куя белү;

-дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм**

-Җанлы һәм җансыз предметларны,рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;

-тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;

-укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;

-үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә информация бирә белү.

**Уку**

-Татар алфавитындагы хәрефләрне таный белү;

-хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;

-дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;

-тексттагы тыныш билгеләренә карата тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү,өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонацияләре белән уку;

-укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;

-кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;

-укыганда сүзлекләр кулана белү.

**Язу**

-Татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;

-дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;

-бәйрәмнәр белән котлау, чакыру кәгазьләре язу;

-конверт һәм дәфтәр тышына яза белү;

-программада күрсәтелгән темалар буенча, терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру.

**<u>Уку елы ахырына универсаль уку гамәлләре формалаштыру. УУГ.</u>**

**Шәхси нәтиҗәләр.**

**Шәхси универсаль уку гамәлләре:**

- “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;

- Туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;

- укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;

- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

**Предметара нәтиҗәләр.**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
- Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
- Укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
- Эш сыйфатына бәя бирә белү.
- Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү.( линейка, бетергеч, карандаш, )

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

- Дәреслек белән эш итә белү.
- Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, экиятне) сәнгатьле итеп уку.
- Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
- Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
- Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
- Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
- Предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
- Укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- Укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт

белдерә белү.

- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- Парларда эшли белү

**II. Укыту предметының эчтәлеге**

УМК өчен материал 1сыйныф балаларының аралашу сфераларын исәпкә алып сайланды.

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: “Әйдәгез танышабыз!”, “Урман дусларыбыз”, “Спорт бәйрәме”, “Мәктәптә”, “Йорт хайваннары һәм кошлары”, “Бакчада”,” Кыш җитте”, “Сәламәт бул!”, “Безнең гаилә”, “Татар халык ашлары”, “Без шәһәрдә яшибез “Кибеттә”, “Җәй”темалары кертелде. Дәреслеккә кызыклы сораулар, чагыштыруны, анализлауны, логик фикерләүне таләп иткән төрле биремнәр кертелде.

**III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру**

| № т/с | Өйрәнелә торган бүлек, уку материалының темасы | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты: | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Планлаштырылган срок | Фактик срок |
| 1. | **Әйдәгез танышабыз** . "Әйдәгез танышабыз!" темасы буенча әңгәмә. Сыйныфташларың, укытучы, китаптагы персонажлар белән танышу. | Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау. | 4.09 | |
| 2. | Синең исемең ничек? соравы һәм аңа җавап формасы | Укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. Дәреслектәге план буенча сөйли белү, дуслашырга тәкъдим итә белү. | 6.09 | |
| 3. | Бу кем?нәрсә? | Әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү. | 10.09 | |
| 4. | Бу күрсәтү алмашлы. | Укытучының соравына җавап бирәләр. **Бу** күрсәтү алмашлыгын сөйләмдә куллану. | 14.09 | |
| 5. | Раслау һәм кире кагу формалары | Парларда үз фикерен әйтәләр.Чагыштыралар. | 17.09 | |
| 6. | Без сорау бирәбез ( мы, -ме) | Яңа материалны үзләштерү буенча үз фикерләрен әйтәләр. (Нәрсәне аңладылар? Нәрсә аңлашылмады? Ни өчен?) | 21.09 | |
| 7. | Бу кайсы шәһәр? соравы. Син кайда яшисең? соравы һәм аңа җавап формасы. | Мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару, фикерне төгәл итеп җиткерү.Ялгызлыкисемнә ренбашхәрефтәнбашлапязу. | 24.09 | |
| 8. | 1 дән 10 га кадәр саннар. *Микъдар саннары белән таныштыру (1-10 саннары).* | Укытучы ярдәме белән максат кую, эшне планлаштыру. | 28.09 | |
| 9. | **Урман дусларыбыз.** Кыргый | Тиешле мәгълүматны | 1.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хайваннар | табу, билгеләү, сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу. [а] авазын дөрес әйтү, а хәрефен дөрес язарга өйрәтү. Кыргый хайваннарның исемнәрен берлектә һәм күплектә куллану. | | |
| 10. | Кыргый хайваннар. Ничә? соравына җавап бирү. | Өйрәнелә торган орфограммаларны ишетеп аңлау. Хәреф элементларын атау, башлану ноктасын билгеләү, үрнәк буенча язу.**Ничә?** соравынаҗавапбирү. | 5.10 | |
| 11. | Урман дусларыбыз темасына сөйләшү. | .Үз хезмәтеңне оештыру. Урман дусларыбыз темасына сөйләшү. | 8.10 | |
| 12. | Урман дусларыбыз. | ***Нинди?***соравы һәм аңа җавап формасы.Әңгәмәдәшенең фикерен тыңлый белү. | ***12.10*** | |
| 13. | **Командалар бирәбез** | Боерык фигыль.турында төшенчәне аңлау. Биремне эшләгәндә, кулланылган кагыйдәне аңлату. | 15.10 | |
| 14. | Акбай нишли | Нишли? соравын куя һәм аңа җавап бирә белү | 19.10 | |
| 15. | Нишлисең? соравы һәм аңа җавап формасы | *Нишлисең?* соравын куя һәм аңа җавап бирә белү | 22.10 | |
| 16 | Кем белән уйныйсың? соравы һәм аңа җавап формасы | *Кем белән уйныйсың?* соравын куя һәм аңа җавап бирә белү | 26.10 | |
| 17 | Син ничәнче? | Ничәнче? соравын куя һәм аңа җавап бирә белү. Предметларның тәртип санын әйтә белү | 29.10 | |
| 18 | **Мәктәптә**. Уку – язу әсбаплары | Уку-язу әсбапларының кирәклеген әйтү, үзеңә сорап алу белү формасы. | 9.11 | |
| 19. | Уку-язу әсбапларының саны, төсе, барлыгы һәм юклыгы | Орфограммаларны табу,билгеләү. Тиешле мәгълүматны табу, билгеләү, сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу. | 12.11 | |
| 20 | Уку-язу әсбапларының кирәклеген әйтү, үзеңә сорап алу | Уку-язу әсбапларының кирәклеген әйтү, үзеңә сорап алу белү формасы. | 16.11 | |
| 21 | Без ничек укыйбыз? | Уку-язу әсбапларының кирәклеген әйтү, үзеңә | 19.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | сорап алу белү формасы. | | |
| 22. | *Кайда?* соравы һәм аңа җавап формасы | Чагыштыралар.Текст укыйлар. | 23.11 | |
| 23. | **Йорт хайваннары һәм кошлары** В,в хәрефе. Сүз басымы. | Сүзләрдә басымны дөрес кую.Дустыңның тышкы кыяфәтен һәм характер сыйфатларын ачуда сүзләрне урынлы һәм аңлап куллану. Йорт хайваннары һәм кошлары исемнәрен хәтердә калдыру. | 26.11 | |
| 24 | *Кая?* сораулары һәм аларга җавап формасы | Әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү; коммуникатив мәсьәләгә таянып фикерне төгәл итеп җиткерү. | 30.11 | |
| 25 | *Кая? сораулары һәм аларга җавап формасы* | Әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү; коммуникатив мәсьәләгә таянып фикерне төгәл итеп җиткерү. | 3.12 | |
| 26 | *Кайдан?* соравы һәм аңа җавап формасы. | Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау. | 7.12 | |
| 27. | **Яшелчәләр** | Яшелчә исемнәренең дөрес язу.Сүзләр, җөмләләр язу. | 10.12 | |
| 28. | Җиләк-җимеәләр. | *Кирәк, кирәкми* сүзләрен дөрес аңлау. Чылбыр буенча кабатлыйлар.Орфограммаларны табу,билгеләү. | *14.12* | |
| 29. | *Нинди?* соравы һәм аңа җавап формасы | **Сыйфат+исем** төзелмәсен сөйләмдә куллану.*Нинди?* соравы һәм аңа җавап формасын аңлап куллану. Укытучының һәм бер-берсенең сорауларына җавап бирәлә | **17.12** | |
| 30 | Мин яратам төзелмәсе. | Нәрсә яратканны, яратмаганны әйтү, сорау формаларын куллану. Әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү; коммуникатив мәсьәләгә таянып фикерне төгәл итеп җиткерү. | 21.12 | |
| 31. | **Кыш билгеләре** | Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү | 24.12 | |
| 32. | Кыш бабай килә. | Кыш бабайга хат язабыз. Эпистоляр жанр текстларын дөрес язу. Үрнәк буенча эшләү. Яңа | 11.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | лексиканы кулланып, хат язуга ирешү | | |
| 33 | *Минем чанам бар* төзелмәсе | Фикерне төгәл җиткерү. | 14.01 | |
| 34 | *Кышкы уеннар*. | Лексик – грамматик күнекмәләрне камилләштерү .Җөмләдә дөрес куллана белү | 18.01 | |
| 35 | Яңа ел бәйрәме | Сүз тәртибен дөрес кулланып җөмләләр төзү. | 21.01 | |
| 36. | Уенга чакыру | Иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру | 25.01 | |
| 37 | Бәйрәмгә барабыз | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | 28.01 | |
| 38. | Уенга чакыру | Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү | 1.02 | |
| 39. | . Тән әгъзаларының исемнәре | Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. Сүз тәртибен дөрес кулланып , җөмләләр төзү. | 4.02 | |
| 40 | Кай җирең авырта? соравы һәм аңа җавап формасы | Зат алмашлыкларын куллану. Сорау җөмләләр төзү күнекмәләрен камилләштерү.<br>Җөмлә ахырында сорау, нокта, өндәү куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү | 8.02 | |
| 41. | Шәхси гигиена предметлары | *Авырта* фигыленең юклык формасын дөрес куллану.Сүз тәртибен дөрес кулланып җөмләләр төзү. | *18.02* | |
| 42 | Шәхси гигиена предметларын сорап алу | Шәхси гигиена предметларының исемнәрен транскрипция белән язу.Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. | 22.02 | |
| 43. | **Безнең гаилә**. Гаилә . | .Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. Сүз тәртибен дөрес кулланып , җөмләләр төзү. (Мин, минем, миңа) | 25.02 | |
| 44 | Минем гаиләм | Җөмлә ахырында сорау, нокта, өндәү куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү | 1.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 45. | Яз җитә | План буенча сөйли белү. | 4.03 | |
| 46. | 8 нче Март – әниләр бәйрәме турында сөйләшү. | Җөмлә ахырында сорау, нокта, өндәү куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү | 8.03 | |
| 47. | Бәйрәм белән котлый белү. | Котлау язу күнекмәләрен мөстәкыйль куллана белү | 11.03 | |
| 48 | **Татар халык ашлары**. | Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. Сүз тәртибен дөрес кулланып , җөмләләр төзү. | 15.03 | |
| 49 | Тәмле ризыклар | Ризыкларның тәмле булуын әйтү. Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау.Матурһәмдөреся зукүнекмәләребулдыру. | 18.03 | |
| 50. | Кунакта | Табын янында үз-үзеңне тоту буенча киңәшләр бирә белү. иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру; | 22.03 | |
| 51 | Кунакны каршы алу. | Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау. | 1.04 | |
| 52 | Кунакны каршы алу. | Кисәкчәләрнең мәгънәләрен ачыклау өстендә эшләү. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы буенча кагыйдәләр үзләштерү, язмада куллану. | 5.04 | |
| 53 | Табын янында | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 8.04 | |
| 54 | Ашамлыклар. | Укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. | 12.04 | |
| 55 | Ашамлыклар. | *Эчә, ашый* фигыльләренең I, II, III затта берлек саны. Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыру | *15.04* | |
| 56. | Ашамлыклар кибетендә. | Кибеттә савыт-саба сатып алу темасына сөйләшү. | 19.04 | |
| 57. | Савыт-саба | Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау. | 22.04 | |
| 58 | Савыт-саба кибетендә темасына сөйләшү. | .Яңа лексик берәмлекләр куллану. Сүз тәртибен дөрес кулланып , җөмләләр төзү. | 26.04 | |
| 59 | Савыт-саба кибетендә темасына сөйләшү. | Яңа лексик берәмлекләр куллану. Сүз тәртибен дөрес кулланып , | 29.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | җөмләләр төзү. | | |
| 60 | Киемнәр. | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 3.04 | |
| 61 | Киемнәр кибетендә | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 6.05 | |
| 62 | Киемнәр кибетендә | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 10.05 | |
| 63 | “Җәй җитә” темасына сөйләшү | Җәйге табигать турында сөйли белү. | 13.05 | |
| 64 | Җәйге ял | Күңелле җәй темасына сөйләшү. Җәйге табигать турында сөйли белү. | 17.05 | |
| 65 | Без Сабантуйга барабыз темасына сөйләшү | Сабантуйда нишләвең турында әйтә белү. | 20.05 | |
| 66 | Без Сабантуйга барабыз темасына сөйләшү | Сабантуйда нишләвең турында әйтә белү. | 24.05 | |